УДК 398.8

*Р.Ф. Хәкимов*

## РЕКРУТ ҖЫРЛАРЫНДА СОЛДАТ ЯЗМЫШЫ

В статье изучаются татарские народные рекрутские песни в плане отражения в них судеб военных служивых.

**Ключевые слова:** татарские народные песни, рекрутские песни, служивые люди.

Татар фольклорындагы тарихи җырлар эчендә рекрутларга (никрутларга) багышланганнары шактый зур тематик төркем тәшкил итә. Алар, гадәттә, җыр җыентыкларында да аерым бүлек итеп урнаштырылалар. Әйтик, композитор А.С. Ключарев редакциясендә 1941 елда дөнья күргән «Татар халык көйләре»нең 1 томында «Рекрут, солдат җырлары» дигән исем астында 7 әсәр бирелгән [Ключарев]. Илбарис Надиров әзерләп бастырган «Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар» томында «Патша армиясе, рекрутлар, солдатлар, әсирләр моңы» бүлеге үзенең күләмле булуы белән үк игътибарны җәлеп итә. Ул 29 җырны эченә ала [Татар халык иҗаты..., б. 71–89]. Ләкин мәсьәләгә башкачарак караш та яшәгән булуы билгеле. И. Надиров язганча, элек бу җырлар, гадәттә, лирик җырлар жанрына кертеп йөртелгән. Солдат җырларында, чыннан да, лиризм көчле, беренче карашка аларның шактыен лирик җырлардан аерып карау мөмкин дә түгел кебек. Әмма, шул ук вакытта, солдат җырларының төп өлешендә хәрби-тарихи чынбарлык сулышы сизелә, алар үзәгендә гаскәри хезмәтнең бөтен кыенлыгын үз җилкәсендә татыган герой тора [Надиров, б. 13].

Рекрутлар төркеменә караган җырлар XVIII гасырда иҗат ителә башлаган (1705 елда Россиядә регуляр патша армиясе оешкач, татарларны да хәрби хезмәткә алу камәлгә кертелә) дип карала. Россия составында булган башка халыклар иҗатында да әлеге темага караган җырларны шактый очратырга мөмкин. Барысының да эчтәлегендә патша-түрәләргә нәфрәт белдерү, аларның хакимлегеннән тирән ризасызлык чагыла. Рус телен, офицерларның командаларын аңламаган башка милләт вәкилләренә бигрәк тә авыр булган. Кыйнау, төрлечә җәберләү шартларында, гаиләсеннән, туганнарыннан аерылып, егерме биш ел буе хезмәт итәргә, әлбәттә, берәү дә атлыгып тормаган, аннан ничек булса да котылырга тырышканнар. Хәтта үз-үзләрен имгәтү, гарипләндерүгә кадәр баручылар күп булган. Солдатка каралганда уздырылган медицина комиссиясеннән «яраксыз» дип чыгарсалар, яшьләр өчен шуннан да зур шатлык булмаган.

«XIX йөздә тарихи җырларның классик үрнәкләре барлыкка килсә, гасыр азагында һәм XX йөз башында жанрның иҗади үсеше дәвам итә. Солдатлар һәм рекрутлар тормышын тасвирлаган җырларның безгә мәгълүм булганнары нәкъ әнә шуны раслый» [Урманчеев, б. 153]. Әлеге әсәрләрдә без хезмәткә алыну хәсрәте, аерылышу, армиядәге авырлыклар сурәтләнешен күрәбез. «Рекрут, төрмә, каторга җырлары – мәхәббәт җырларына караганда, бөтенләй башка характерда», – дип басым ясап күрсәтә В.Я.Пропп [Пропп, с. 10]. Рекрут җырларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин:

1) рекрутлыкка алынучылар җырлары;

2) хезмәткә алынучыларның якыннары тарафыннан чыгарылган җырлар;

3) армиядәге хезмәт турындагы җырлар.

Бу төркемгә караган җырларның максаты конкрет бер тарихи шәхесне геройны сурәтләү түгел, ә шул чорда халык башыннан үткән вакыйгаларны тасвирлау. Әсәрләрдәге образларның кичерешләре алар хәлендәге башкаларныкы белән уртак, бердәй булганга, җыр сүзләре күпләрнең рухына якын булып әверелә.

Солдат хезмәтенә китә торган егеткә туган йортын гына түгел, бәлки туган җиреннән, якыннарыннан-газизләреннән дә аерылырга туры килгән. Җырларда әйтелгәнчә, күпләр мондый аерылуны үлем белән тиң күргән. Хезмәткә алынучыларның берсе дә өйгә исән-сау кайтырбыз дип ышанмаган, чөнки, төрле сугышлар еш булып тору сәбәпле, күп кенә солдатлар, чынлап та, әйләнеп кайта алмаганнар.

Карлыгачлар кайтыр язлар җиткәч,
Мин кайталмам кебек бер киткәч.
Ачы икән алманы ашавы,
Авыр икән илләрне ташлавы.

«Әнекәем, монда килсәнә»

Җырларда әти-әнисенә үпкә белдергән юлларны очратырга мөмкин, чөнки чиновникларга ришвәт бирү хисабына рекрутларны хезмәттән алып калу очраклары да аз булмаган.

Быел җәйне урак урдым
Ике беләгем сызганып,
И әнкәем, ике беләгем сызганып;
Бәне эткәй солдат итте,
Бер эскертен и кызганып,
И әнкәем, бер эскертен и кызганып.

«Никрут йөкләнде муйныма»

Кайберәүләр солдатка алынудан үлемне хәерлерәк күргәннәр:

Әйдәгезче, дуслар, озатыгыз,
Шул Инсар тауларын менгәнче;
Җан бирүем җиңел булыр иде,
Прием ишегеннән кергәнче.

«Никрутлар җыры»

Инде әйтелгәнчә, үз-үзләрен хезмәткә яраклы итеп күрсәтәсе килмичә, сәламәтлекләренә зыян салучылар да булган, гади халыкны бигрәк тә гаделсезлек тойгысы изгән. Чөнки еш кына, бай балалары урынына саулыгы зәгыйфь фәкыйрьләрне җибәргәннәр.

Икенче төркемдәге җырлар солдат аналары тарафыннан иҗат ителгәннәр, олыгайган көннәрендә ярдәмче-таяныч булыр дип үстергән улыннан аерылу ана өчен зур фаҗига булган.

Кыр да капкаларын чыккан чакта,
Өзеп кенә каптым бер миләш;
Син дә бәбекәемнән аерылгач,
Кемнәр бирер миңа бер киңәш?

Күп кенә ата-ана егерме биш ел буена балаларын көтеп ала алмаганнар, озату мизгелләре аларның соңгы очрашулары булган.

Комиссиядә «хезмәткә яраклы» дип каралганнан соң, яшьләрнең озакка сузылган «никрут» тормышы башланган. Аларның туган җирен, туганнарын ташлап китү газапларына армиядәге түзеп булмаслык шартлар, офицерларның мыскыллаулары да килеп өстәлгән (бигрәк тә мөселман егетләренә).

Әфицәрләр юкка суктырдылар,
Басурман, дип көләләр үзләре;
Мәңгелеккә «сагынмалык» калды
Аркамдагы шумпыл эзләре.

Әлбәттә никрутлар арасында мондый җәберләүләргә түзә алмыйча, көчле протест белдерүчеләр дә табылган. Андыйларның солдат срогы төрмәләрдә тәмамланган «Егерме ел солдат булып йөрдем» җыры нәкъ шундыйларның берсе.

Түзә алмадым, дуслар, бу хурлыкка,
Янаралның битенә төкердем;
Мине рисвай иткән әфицәрне
Аркасыннан чәнчеп үтердем...

...Ай-һай хурлык күрдем, ачлык
күрдем,
Этләр күрмәгәнне мин күрдем;
Егерме ел солдат булып йөрдем,
Яшь үмрем төрмәдә бетердем.

«Тарихи җырларда чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт күбрәк трагик, драматик һәм героик планда чагылыш таба», – дип яза профессор М.Бакиров [Бакиров, б. 177].

Әлбәттә, «героик» дигәндә, беренче чиратта халыкка хас, халык күрсәткән батырлык күздә тотыла. Ләкин «Егерме ел солдат булып йөрдем» җырындагы солдатның ерткыч офицерга кул күтәрүе шулай ук батырлыкның (стихияле төстә булса да) бер чагылышы. Ләкин никрутларның трагедиясе аерым командирларга гына кайтып калмый. Монда төп сәбәп илдәге идарә системасында. Никрут җырларында шундый мотивлар торган саен ачыграк яңгыраш ала.

Алдыбызда аккан, әй, агым су,
Кармак салдым шунда балыкка;
Явыз патшаларның малы өчен
Тереләй салалар бит тамугка.
«Газиз башым»

Элекке солдат җырларына игътибар иткән һәрбер кеше безнең халыкның иске армиягә нинди мөнәсәбәттә булганлыгын бик ачык күрә ала. Солдат җырлары да, башка лирик җырлар кебек үк, халык тормышының иҗтимагый тарихын бик матур чагылдырган елъязмалар булып хезмәт итәләр [Татар халык иҗаты, б. 208].

**Әдәбият**

*Бакиров М.* Тарихи җырлар // Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 176–197.

*Ключарёв А.* Рекрут, солдат җырлары // Татар халык көйләре. Казан. Татар. кит. нәшр., 1941.

*Надиров И.* Татар халкының тарихи җырлары һәм лирик озын җырлары турында // Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 5–32.

*Пропп В.Я.* Фольклор и действительность. Избранные статьи. М., 1976.

Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

*Урманчеев Ф.* Тарихи җырлар // Казан утлары. 1969. № 3. Б. 132–148.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 307 б.

***Хәкимов Рәдис Фәрит улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
.........................................